**КАРАР**

**08 апрель, 2024 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Балыклы авылында «Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Балыклы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 2 номерлы Балыклы авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 06 апрелендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Балыклы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 27 ноябрендәге 2 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге Балыклы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокլы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Балыклы авылы өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урам яктыртуны рәтләү һәм карап тоту; смета документларын эшләү;
- Балыклы авылының яр буе зонасын төзекләндерү һәм карап тоту, шул исәптән смета документларын эшләү;
- Балыклы авылының чишмәсен һәм коесын төзекләндерү һәм карап тоту, смета документларын эшләү;
- Балыклы авылының су белән тәэмин итү челтәрләрен рәтләү, карап тоту һәм ремонтлау, смета документларын эшләү;
- урам юл челтәрен карап тоту, Балыклы авылындагы күпернең култыксаларын ремонтлау, смета документларын эшләү

2023 елның 27 ноябрендәге 2 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементларен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау, Балыклы авылы өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Балыклы авылының яр буе зонасын төзекләндерү һәм карап тоту, шул исәптән проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (Балыклы авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен һәм су суырту манараларын рәтләү, карап тоту һәм ремонтлау, материаллар сатып алу, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Балыклы авылы чишмәләрен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, култыксалы баскыч урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);
- коеларны рәтләү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; (Балыклы авылы коеларын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, коймалау, материаллар сатып алу, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, коеларны төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юл челтәрен кышын карап тоту, Балыклы авылындагы күпернең култыксаларын ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 264 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 134 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 134 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Балыклы авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез Кукмара муниципаль районы Балыклы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 27 ноябрендәге 2 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге Балыклы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Балыклы авылы өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урам яктыртуны рәтләү һәм карап тоту; смета документларын эшләү;
- Балыклы авылының яр буе зонасын төзекләндерү һәм карап тоту, шул исәптән смета документларын эшләү;
- Балыклы авылының чишмәсен һәм коесын төзекләндерү һәм карап тоту, смета документларын эшләү;
- Балыклы авылының су белән тәэмин итү челтәрләрен рәтләү, карап тоту һәм ремонтлау, смета документларын эшләү;
- урам юл челтәрен карап тоту, Балыклы авылындагы күпернең култыксаларын ремонтлау, смета документларын эшләү

2023 елның 27 ноябрендәге 2 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау, Балыклы авылы өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Балыклы авылының яр буе зонасын төзекләндерү һәм карап тоту, шул исәптән проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (Балыклы авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен һәм су суырту манараларын рәтләү, карап тоту һәм ремонтлау, материаллар сатып алу, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, төзекләндерү буенча башка эш төрләре);
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Балыклы авылы чишмәләрен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, култыксалы баскыч урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);
- коеларны рәтләү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; (Балыклы авылы коеларын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, коймалау, материаллар сатып алу, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, коеларны төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам-юл челтәрен кышын карап тоту, Балыклы авылындагы күпернең култыксаларын ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Маликов

ОГРН 1021607754657
ИНН 1623001879